**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"25" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 25 ноябрендә «Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- авыл урамына җәю өчен вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2.Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү;

3. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру, һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 30 (утыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 20 (егерме) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 20 (егерме) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Мондеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- авыл урамына җәю өчен вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2.Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү;

3. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру, һәм хезмәтләр өчен түләү; мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Салахов И.И.

Совет Кунгерского сельского поселения
Күңгәр авыл җирлеге советы
ИНН 1610000791